**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР №29**

Урыссу штп 26.10.2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 06.06.2023 ел, №9 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 06.06.2023 ел, 9 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 17 статьясы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте, муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты билгеләгән дәүләт (муниципаль) программаларының исемлеге һәм структурасы нигезендә, бюджет чыгымнарының һәр максатчан маддәсе буенча бюджет турындагы карар белән раслана.

Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр җирлек башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән срокларда расланырга тиеш.

Муниципаль программалар үз көченә кергән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча бюджет турындагы карарга туры китерелергә тиеш.».

1.2. Нигезләмәнең 16 статьясындагы 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә, муниципаль программалар буенча, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча төзелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы
поселогы башлыгы, Совет рәисе А.Ә. Шәфигуллин